**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**L СЕССИЯ**

# КАРАР № 6

Спас авылы «20» май 2019 ел

**Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XLIX сессиясенең “Спас авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада булучыга, яше җитеп, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, бер тапкыр акчалата бирелә торган түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында”гы бнчы карарга үзгәрешләр кертү турында**

---

Законга үзгәреш кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Спас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Спас авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XLIX сессиясенең “Спас авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада булучыга, яше җитеп, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, бер тапкыр акчалата бирелә торган түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында”гы бнчы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

*1.1. 2нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Спас авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада булучы затка (арытаба – муниципаль вазыйфадагы зат), пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә эштән киткәндә (закон нигезендә – яше җитеп, картлык яисә инвалидлык нәтиҗәсендә эшкә сәләте югалуга бәйле рәвештә иминият пенсиясе алуга хокук бирә торган яшькә җитүгә бәйле), әгәр ул зат Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Спас авыл җирлеге” муниципаль

бераммлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфада кимендә бер тулы срокта хезмәттә булган, муниципаль яки дәүләт вазыйфаларында гомуми эшләү стажы 15 елдан да ким булмаса, Татарстан Республикасының 2009 елның 12 февралендә чыгарган "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкаләтлле органы депутаты, жирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, жирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы №15-ЗРТ Законына туры китереп, пенсиягә өстәмә түләү хокукы булганда, аның эштән киткән көнгә кадәр биләгән вазыйфасында билгеләнгән айлык хезмәт хакының бишләтелгән күләмендә бер тапкыр түләү бирелә, шуннан соңгы һәр ел өчен өстәмә рәвештә 0,5 берәмлек күләмдә акчалата түләү өстәлә, әмма муниципаль вазыйфадагы кешенең айлык акчасының унлатылган күләменнән артыграк түгел."

2. Әлеге карарны жирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Спас авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **А.В.Ишкова**